XX гасыр ахырында, җәмгыятьтә барган үзгәртеп корулар тәэсирендә иҗтимагый-сәяси карашларда, мәдәни кыйммәтләргә мөнәсәбәттә тамырдан үзгәрешләр күзәтелә. Алар барысы да әдәбиятта, шул исәптән, драматургиядә дә чагылыш таба. «Күчеш чоры» буларак бәяләнгән әлеге дәвердә татар сәхнә әдәбияты сан һәм сыйфат ягыннан җитди үзгәреш кичерә. Бу, бер яктан, сурәтләнгән тормыш материалына бәйле, тематик һәм жанр төрлелегендә, икенче яктан, әдипләрнең әдәби-эстетик эзләнүләренә нисбәтле, актив рәвештә яңа алым-чараларга мөрәҗәгать итүендә чагыла. Драматурглар шартлылыкның, метафора булып килгән күренешләрнең, символларның бай палитрасын, мифларны һәм архетипларны, шулай ук реализм һәм романтизмга, модернизм һәм постмодернизмга хас алымнарның (аеруча «шизоанализ», «уен», аңсызлык белән бәйле чиктәш халәт, лиризм һәм фаҗигалелекнең үрелеп баруы, ике дөнья күренешен бирү һ.б.) үзара синтезлашуын сурәтләү аша яшәешне милли эчтәлекне саклаган хәлдә, бөтен тулылыгында һәм каршылыгында укучы-тамашачы күз алдына бастырырга омтылалар. Тормыштагы каршылыкларны, битарафлык һәм икеләнүле халәтне үтеп чыгу, яшәештә гармониягә омтылу һәм, шул максатта, сурәтләүнең яңа юлларын эзләү хәзерге татар сәхнә әдәбиятында мифологик күзаллаулар, архетиплар белән кызыксынуның көчәюенә китерә.

Билгеле булганча, мифология борынгы кешеләрнең дөньяны танып белү формасы булып тора. Мифологик күзаллау кешеләрнең әйләнә-тирә дөньяны төрле образлар, геройлар аша кабул итүе белән бәйле [1: 20], шуңа да анда Галәм, Җир һәм Кеше яратылышы, шулай ук яшәеш өчен аеруча кирәкле хәл-күренешләр тәртибе аңлатыла. «Тормышта билгеле бер тәртип урнаштыручы һәм шуны тайпылышсыз саклаучы мифлар борынгы җәмгыятьнең рухи нигезен тәшкил иткәннәр» [2: 9]. Шуңа да мифология матур әдәбиятның җирлеге булып тора. Ю.Лотман һәм З.Минц билгеләп үткәнчә, әдәбият мифның җимерелгән, аерым өлешләре генә сакланган формасын файдалана һәм үзе дә әлеге җимерелүгә актив хезмәт итә. Бу күренешнең тагын бер үзенчәлеге шунда: миф әдәби текстка еш кына автор теләгеннән башка үтеп кереп, әсәрне фәнни тикшерү барышында гына табыла һәм ул әдәбиятның һәр чорында

күзәтелә. Әйтик, күпсанлы әсәрләрдә халык тарихына бәйле урын алган инкыйлаблар, сугышлар, тарихи шәхесләр, милли яшәеш кыйммәтләре автор аңында туган шартлы дөнья белән бәйле булса да, ул реаль чынбарлык моделе буларак тәкъдим ителә [3: 29-33]. Мифология һәм әдәбиятның үзара бәйләнеше мәсьәләсе галимнәрне күптәннән кызыксындыра, әмма ул бары XIX гасырда гына, Европада бертуган Я.В.Гриммнар, И.Гердер, Ф.Шеллинг, ә рус фәнендә Ф.Буслаев, А.Афанасьев, А.Потебня, А.Веселовский исемнәре белән бәйле, фәнни юнәлеш буларак формалаша һәм үсә башлый. XX гасырда мифологик танып белү процессының табигатен өйрәнүгә бәйле яңа концепцияләр тәкъдим иткән Э.Кассирер, К.Леви-Строс, К.Г.Юнг эшчәнлеге әлеге фәннең үсеш-үзгәрешенә зур йогынты ясый. Рус фәнендә, мифологизм, аның төрле тармакларының килеп чыгышы, типологиясе, эстетик һәм яшәеш үзенчәлекләре, шулай ук аның әдәбият, тарих, социология, психология белән катлаулы бәйләнеше В.Я.Пропп, А.Ф.Лосев, М.М.Бахтин, Е.М.Мелетинский, А.Е.Хализев, В.Н.Топоров һ.б. тарафыннан өйрәнелеп, җитди казанышларга ирешелә. Татар әдәбият фәнендә мифологик күзаллауларга бәйле беренче хезмәтләр XIX гасырның икенче яртысында К.Насыйри тарафыннан языла [4]. Мәгърифәтче галим фольклор әсәрләрен, шул исәптән халык арасында киң таралган йолаларны, ышануларны, гореф-гадәтләрне җыю, туплау белән генә чикләнмичә, аларны фәнни нигезләү, бәяләү омтылышын да ясый. Әмма аның «эзләнүләрендә миф атамасы кулланылмый» [2: 3], фәнни юнәлешкә әле киң планда нигез салынмый [5: 48-50]. XX гасырда мифологияне өйрәнү фольклорчы галимнәр тарафыннан билгеле бер дәрәҗәдә алып барылса да (Х.Ярми, Җ.Алмаз, Х.Мәхмүтов, И.Надиров, Ф.Урманче, Л.Җамалетдинов, Ф.Баязитова һ.б.), «әдәбиятта халык иҗатына, мәҗүси һәм аеруча мөселман мифологиясенә игътибар нык кими» [2: 177]. Бары XX-XXI гасырлар чигендә мифологиягә бәйле җитди тикшеренүләр башлана. М.Бакиров [1], Г.Гыйльманов [6], М.Мәһдиев [7], Р.Уразманова [8], А.Яхин [9], хезмәтләрендә татар мифологиясе, аның башлангычы, үсеш-үзгәреш үзенчәлекләре өйрәнү предметы булып торса, мифологиянең хәзерге татар әдәбиятында чагылышы, яңа миф тудыру үзенчәлекләре, аның әдәби-эстетик аспектлары Ф.Урманче [10-11], Й.Нигъмәтуллина [12], Д.Заһидуллина [13], Г.Гыйльманов [6], А.Шәмсутова [14] һ.б. хезмәтләрендә чагылыш таба. М.Ибраһимовның «Миф в татарской литературе XX века. Проблемы поэтики» [15] хезмәтендә татар әдәбияты үрнәкләре нигезендә мифологизмның теоретик аспектлары, аны тикшерү юллары өйрәнелә. Л.Дәүләтшинаның «Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI вв.» [16] хезмәтендә хәзерге әдәби процесска бәйле мифологизм күренешенең үзенчәлекләрен ачыклау, аны анализлауның яңа принципларын эзләү омтылышы ясала. Шул рәвешле, мифология һәм әдәбият бәйләнешләренә нисбәтле аерым бер хезмәтләр булса да (аларда, нигездә, прозага һәм поэзиягә караган әсәрләр тикшерелә), хәзерге драматургиягә бәйле аерым авторлар иҗатында мифның функцияләрен, аңа мөрәҗәгать итү сәбәпләрен, әсәрләрнең поэтик үзенчәлеген өйрәнү җитди мәсьәлә булып кала.

Мифларның борынгы моделе кешенең табигать дөньясында һәм ыру-кабилә мөнәсәбәтләрендә үз урынын табарга, шуларга җайлашырга омтылу нәтиҗәсендә туган психологик һәм физиологик эмоцияләрнең чагылышы булган курку, җенси теләк, шатлану, ачулану, гаҗәпләнү һ.б. га нигезләнә. Язма әдәбият, билгеле, сюжетларны беренче мифологиядән ала. Шул ук вакытта, фольклорда һәм язма әдәбиятның беренче үрнәкләрендә үк мифларны үзгәртеп куллану да күзәтелә. Бу борынгы мифларны яңача уку, алардагы аерым сыйфат-билгеләрне заманга яраклаштырып аңлату теләге белән бәйле. Л.Дәүләтшина билгеләп үткәнчә, «әдәби мифологизмга мифик аңның семантик элементларын яңадан тудыручы дөньяның мифологик моделен төзү хас» [16: 27].

Татар сәхнә әдәбиятында мифологиягә мөрәҗәгать итү һәр әдәби-тарихи этапта күзәтелә һәм аның кулланылышы да үзгәреш кичерә. Татар драматургиясе XIX йөзнең соңгы чирегендә генә мәйданга килсә дә, тизләтелгән юл узып, XX йөз башында үзенең төп жанрларын булдырган, реалистик һәм романтик сурәтлелек принципларын үзләштергән, модернистик алымнарны да чит итмәүче әдәби төр буларак чыгыш ясый. Г.Камал, Г.Исхакый, С.Рәмиев, Г.Коләхмәтов, И.Богданов, Ф.Әмирхан, М.Фәйзи, К.Тинчурин, Ф.Бурнаш пьесаларында милли яшәешнең җитди мәсьәләләре реалистик һәм романтик планда сурәтләнә.

Татар әдәбиятында «милли тарихны, үткәндәге батырлар һәм фидакарьләрне мәдәни мәйданга чыгару, ислам диненнән мәгълүм шәхесләрне һәм детальләрне, әдәби мотивларны уйнату, боларны халыкка күрсәтү, милли аңда ныгыту эше милләтне үстерү бурычының бер магистраль юлы итеп карала» [13: 162]. Драматурглар чынбарлык күренешләрен бинар оппозицияләрдә (яңалык/искелек, матурлык/ямьсезлек, җәдиди/кадими, яхшылык/начарлык, мәхәббәт/нәфрәт һ.б.) чагылдырып, татар милләтен алга җибәрүгә, яңарышка ирешүгә, кешенең тормышта үз урынын табуына, бәхетле булуына йөз тоталар. 1920 елларда фикер төрлелеге билгеле бер дәрәҗәдә сакланып, борынгы дәверләрдән килгән һәм дини мифларга (Һ.Такташ «Җир уллары трагедиясе», 1922) мөрәҗәгать итүләр булса да, алга таба алар әдәбияттан кысрыклап чыгарыла, ә алгы планга, тарихи, социаль, мәдәни шартлар йогынтысында, «яңа дөнья төзү һәм яңа кеше тәрбияләү турында миф» [17: 159] тудыру чыга. 1930-80 еллар драматургиясендә мәҗүси, аеруча дини мифология чагыштырмача аз урын ала. Шулай да бу елларда халык иҗаты белән яисә риваять-легендаларга нисбәтле байтак әсәрләр иҗат ителә. Арада М.Җәлилнең «Алтынчәч» (1939), Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» (1939), «Идегәй» (1941), «Муса Җәлил» (1957), А.Гыйләҗевнең «Киек каз юлы» (1960), Т.Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» (1974), «Әлдермештән Әлмәндәр» (1975), Р.Батулланың «Пәһлеваннар иле» (1977), «Сират күпере» (1986), Ә.Баяновның «Алтын кашбау» (1986) һ.б. кебек әсәрләре киң яңгыраш таба. 1980 еллар ахырында идеологик чикләүләрнең алып ташлануы, халыкның тирән мәдәни катламнары белән кызыксыну нәтиҗәсендә мифология һәм әдәбият бәйләнеше яңа баскычка күтәрелә.

Хәзерге татар драматургиясе һич тә бертөрле түгел. Әдипләрнең тормыш-чынбарлыкны күзаллау үзенчәлегенә, яңа әдәби дөнья тудыру омтылышына, әдәби-эстетик карашларын яңа алымнар ярдәмендә укучыга җиткерү теләгенә бәйле, мифологиядән файдалануның башка төрләре белән очрашабыз. Бер төр пьесаларда борынгы мифологиядән файдалану алга чыкса, икенчеләрендә автор тудырган текстта, кеше аңының чагылышы буларак, гомумиләштерелгән, универсальлеккә дәгъва иткән образларның, вакыйга-күренешләрнең урын алуы күзәтелә, өченчеләрендә үткән чорларның китап укучылар аңында милли культура, милли аң чагылышы буларак урын алган язучы образына яисә әсәрләргә мөрәҗәгать итү чагылыш таба. Тикшерү предметына нисбәтле, борынгы мифологиягә мөрәҗәгать итү, аны үз әсәрләрендә файдалануның уңышлы үрнәкләре Р.Хәмиднең «Актамырлар иле» (1989), М.Гыйләҗевнең «Бичура» (1989), З.Хәкимнең «Су төбендә сөйгәнем» (1995), «Шайтан куентыгы» (1995), «Телсез күке» (2003), Р.Зәйдулланың «Саташкан сандугач» (2000), «Ашина» (2007), Д.Салиховның «Баязит» (2010) пьесаларында күзәтелә. Борынгыдан килүче мифологик образлар яңа чор әдәби әсәрләрендә яңа эчтәлек белән байый, трансформацияләнә. Моның нигезендә, беренче чиратта, авторның әдәби-эстетик карашлары, ягъни әлеге әсәрендә мөрәҗәгать иткән мифик образ яки күренеш ярдәмендә заман укучысына җиткерергә теләгән фикере ята. Шул ук вакытта, башка факторларның да тәэсире булу бәхәссез. Мисал өчен, хәзерге татар прозасында миф чагылышын тикшергән М.Ибраһимов язучыларның мифологиягә мөрәҗәгать итүенә йогынты ясаган түбәндәге сәбәпләрне аерып чыгара: тарихи-мәдәни хәл, авторның дөньяга шәхси карашы, әсәрнең жанры [15: 43].

Р.Хәмиднең «Актамырлар иле» трагедия-реквиумында милләт язмышы, аңа янаган юкка чыгу, ассимиляцияләшү куркынычы гыйбрәтле күренешләрдә ачыла. Пьесаның төп конфликты өлкән буын белән милли яшәү рәвешен кире каккан яшь буын арасында барлыкка килә. Шуларга бәйле автор авылларның таркалуы, гореф-гадәтләрнең юкка чыгуы, әхлаксызлык күренешләренең артуы, эчкечелекнең тирән үтеп керүе, ата-ана белән бала арасында рухи бәйләнешнең югалуы кебек гаять актуаль мәсьәләләрне алга куя. Әхлакый кыйммәтләрне санга сукмаган буын шундый ук нәсел калдыра дип саный драматург. Мөштәри картның кызы Фаягөл никахсыз бала табып, аны чүпрәккә төреп, чүплеккә ыргыта. Очраклы рәвештә килеп чыккан Борһан баланы коткара. Анасы салган эздән улы Гәрәй дә атлый. Ул елаган баласын ана дуңгыз янына сала һәм сабыйның тапталып үлүенә дә сәбәпче була.

Трагедиядә Мөштәри карт бер риваять сөйли: *«Бик борынгы заманнарда бу урында көчле һәм азат халык яшәгән. Актамырлар ыруы дип аталган ул. (...) Гаҗәеп матур халык булган ул! Алдашу белән хәйләне, куркаклык белән хыянәтне белмәгәннәр алар. Тик алар хәзерге кешеләргә охшамаган булганнар: бер-*

*берсенә гашыйк булганчы гына, адәм сурәтендә йөргәннәр. Егет белән кыз беренче тапкыр үбешүгә, чәчәккә күмелгән агачка әйләнеп, җиргә тамыр җибәрә торган булганнар, имеш. (...) Бервакыт бу якларга икенче төрле ыру килеп чыга. Күктамырлар ыруы дип аталган анысы. Ике арада тарих күрмәгән орыш-талаш китә башта. Тора-бара, солых төзеп, ике ыру бергә аралашып яши башлый. Тик актамырлар ыруы өчен бик хәтәр солых була ул: күктамырларга актамырлар арасыннан кем кушылса да, күктамыр агачына әйләнә икән. Бары рухлары бик көчле булган актамырлар гына үз төсләрен саклап кала алганнар, ди. Менә ни өчен безнең як урманнарда күбрәк күк төстәге агачлар очрый, имеш... ».* Актамырлар иле турындагы риваять авторга катнаш никахның милләт язмышына куркыныч ясавын ачуга хезмәт итә. Балаларының ата-ана фатихасын санга сукмавы, өч кызының да рус егетләренә кияүгә чыгуы, берәүләрнең атасы баш сөягеннән ясалган тустаганнан аракы эчүе кебек хәл-күренешләрне күз алдыннан үткәргән Мөштәри картның йөрәге түзми – ул егылып үлә. Шул рәвешле, әсәрдә милләт язмышы мәсьәләсе яшәү фәлсәфәсе буларак күтәрелә. Әсәр ахырында Кифая карчык белән яшь хатын Фәридәнең уенчык курчакны юындырулары, шул ук вакытта яңгыраган халык җыры пьесада сурәтләнгән фаҗиганең сәбәбен аңларга һәм аны булдырмау юлларын эзләүгә булыша. Драматург милли асылыбызны яклау һәм саклау, гасырлар дәвамында сыналган гореф-гадәтләргә, традицияләргә тугры булу, әхлакый кыйммәтләргә нигезләнеп яшәү кирәклеге турында кисәтә.

М.Гыйләҗевның «Бичура» драмасында кеше күңеленең ике ягын – өмет һәм өметсезлек, яктылык һәм караңгылык, яхшылык һәм явызлык, тугрылык һәм мәкер чагылышын сурәтләү үзәккә куела. Кеше күңелендә мәңгелек көрәш бара. Үзара каршылыкта булган көчләрнең Якты ягы (Яхшылык) өстенлек алса, кешедә киләчәккә ышану, бәхеткә омтылыш баш калкыта, Караңгы ягы (Явызлык) җиңүе исә өметсезлек, ялгызлык, яшәешнең мәгънәсезлеге булып чагыла. Автор драмада Яктылыкны Бичура образы аша бирә. Бичура – халык мифологиясендәге «кычкыра, уйный, көлә, шаяра, йоклый торган кешене бер урыннан икенче урынга күчереп куя» торган *Бичура* һәм «хуҗага файдалы эшләр эшли» [4: 259] торган *Өй* иясен аңлатучы мифик затларның уртак образы.

Текстның мифопоэтик төзелешенә хас булганча, пьесада реалистик һәм мифологик күренешләр үзара бәйләнеп килә. 70 яшьлек Аксак карт үзенең Бичурасын күрә, бу – аның күңелендәге үзгәрешләр билгесе. Ул Кара җаннарның үз күңелләрендәге куркаклык, битарафлык кебек начар сыйфатларның чагылышы булуын аңлый. Озын гомер кичергән карт хәзер инде яшәешкә башка күз белән карый, үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында уйлый, борчыла. Вакыйгаларда тоталитар җәмгыятьнең миһербансыз йөзе калкып чыга, кешегә йөге белән кайгы-хәсрәт, газаплы тормыш, кан-яшь китергән системага нәфрәт яңгырый. Бу юкка түгел. Аксакның йорт-җирен җимерергә, нәселен корытырга теләгән Кара җаннар ул – кешелексез җәмгыять. М.Гыйләҗев Бичура образына ике зур бурыч йөкли: берсе – кешене әлеге тышкы золымнан саклап тору (кызганыч ки, әйләнә-тирә яшәешкә объектив бәя бирүдә карт әлегә ялгыз, «авылның гына түгел, тирә-якның соңгы кешесе»); икенчесе – кеше күңелендә киләчәккә өмет, ышаныч, шатлык хисләрен торгызу. Кеше үз бәхетен, чын яшәешне җаны-тәне белән үзе яшәгән җирне яратканда, шунда хезмәт иткәндә генә таба. Яңа тормышка чыгу өчен, Кара җаннардан – рухыбызны кысып торучы идеология сөременнән, куркаклыктан, мескенлектән котылырга кирәк.

Пьесадагы хәрәкәтне тәшкил иткән конфликт ике катламда бара. Берсе – Аксак күңелендәге Ак һәм Кара як, ягъни Бичура һәм Кара җаннар эш-гамәленә барып тоташучы каршылык, ул Бичура дөньясы белән бәйле. Икенчесе исә реаль тормышта Аксак белән әйләнә-тирәдәгеләр арасында. Соңгысына бәйле экчечелекнең артуы, кеше күңеленең кырыслануы, авылларның бетүе, өлкән буын белән яшь буынның үзара аңлаша алмавы өчен дә, тирәнтен борчыла автор. М.Гыйләҗев укучы-тамашачыны «Кеше кем ул?», «Ул нигә яши?, Яшәү мәгънәсе бармы, ул нәрсәдә?», «Кеше үз-үзен танып белә аламы?» һ.б. шундый фәлсәфи сораулар турында уйланырга этәрә. Драматургиядә пьесаны интеллектуаль тенденция чагылышы буларак тикшергән Н.Йосыпова болай дип яза: «Бичура шартлы-символик образы укучы аңында матурлыкка омтылыш, җан сакчысы, рухи яшәеш, иман билгесе, авырлыкларны җиңәргә ярдәм итүче кебек архетипик сыйфатларга ия образ буларак гәүдәләнә» [18: 138]. Шулай да шатланырга иртә әле. Бичура урынына чормага менеп

утырган Аксакны төшерәбез дип, Күрше, чорманы ишеп, йортны төбәсез калдыра. Автор Аксакның Бичура вазифасын башкара алмавын символик формада күрсәтә. Хәзер инде ул күңелендәге өметне җуйган, һәрнәрсәгә битараф карт буларак сурәтләнә. Күрше карчыгы Хәмдиягә җиде улының, иренең сугышта үлеп калуын, җиде бәбкә белән ата казы да булмавын әйтеп, аның күңелендәге соңгы өметне сүндерә.

Заман кешесе турында уйлану-тикшеренүләренә нигезләнгән автор концепциясенең мифологема, шартлылык, билге-символлар аша чагылуы, ике төрле дөнья моделе төзү, ялгызлык һәм сызлану мотивларын уңышлы куллану һ.б. пьесаны постмодернистик әдәбият кысаларына кертеп карау мөмкинлеге бирә. Әсәрдә йорт үзенчәлекле символик образ булып тора. Тар мәгънәдә, ул Аксак һәм Хатын яши торган нигезне, аларның нәселен аңлатса, киң мәгънәдә без яши торган җәмгыятьне күз алдына бастыра. Аксакның күңелендәге Кара җаннарга каршы көрәше гаиләсен, нәселен, милләтен һәм җәмгыятьне һәр төр явызлыктан саклау булып та аңлашыла. Әсәр ахырында алга чыгарылган төбәсез йорт ул – җимерек дөнья. Нәкъ шушы хәл Аксак күңелендәге өметне сүндерә, Бичурасын югалтуга китерә. Шул рәвешле, Бичура турындагы миф әдәби әсәрнең сюжет чыганагы булып тора, һәм мифик образ авторга кеше күңелендәге каршылыкларны ачуга, җәмгыятьтәге социаль-иҗтимагый һәм милли мәсьәләләрне калкытып бирүгә хезмәт итә.

Яшәешнең җитди мәсьәләләре турында тирән уй-фикерләргә, бәхәсләргә китерүче пьесаларның берсе – З.Хәкимнең «Су төбендә сөйгәнем» комедиясе. Автор, Су анасы турындагы мифтан һәм Г.Тукай эшкәртүендә һәр татар кешесенә таныш булган Су анасы образыннан файдаланып, үз чоры татар җәмгыятенә пародия тудыра. Мәҗүсилек чорыннан килгән мифларда Су анасы төрле (капма-каршы) сыйфат-билгеләрдә чагылыш таба. Ә менә Г.Тукайда традицион мифологик сюжет, яңа эчтәлек алып, үзгә функция үти. Д.Әзһәмова фикеренчә, Г.Тукай поэмасы нигезенә башкаларның әйберен урларга ярамый дигән идея салынган. Шул рәвешле, «мәгърифәтчелек идеологиясе Тукай иҗатында традицион дөнья сурәтенең үзгәрүенә этәргеч бирә»[1] [19: 124]. Реалистик һәм фантастик күренешләр үрелеп киткән, бер караганда, кеше ышанмастай хәлләр тормыштагы ямьсез, әхлаксыз, җан әрнеткеч күренешләрне ача. Әсәр төзелешендә «абсурд театры» элементлары, вакыйга-күренешләрнең, бер-бер артлы килеп һәм өстәлә барып, коллаж төсен алуы, төп геройларның эш-гамәлендә ачык чагылган «уен» алымы чынбарлыкны хаос төсендә кабул итүгә китерә. Постмодернистик концепциягә нигезләнгән пьесада үз чоры татар җәмгыятенә үтеп кергән эчкечелек, рухи матурлыкны югалту, үзара мөнәсәбәтләрдә татар менталитетына хас билгеләрнең юкка чыгуы, һәртөр җитәкчеләр белән халык арасында аңлашылмаучылыкның арта баруы кебек күренешләр бөтен тулылыгында ачыла. Вакыйгалар барышында безгә таныш мифның җимерелүе («Су төбендә сөйгәнем»дә Су анасы образының безгә таныш сыйфатлары юкка чыгу күбрәк әсәрнең жанры белән билгеләнә» [15: 43]) яшәештәге торгынлык һәм ямьсезлекне тагы да аяныч итеп күрсәтүгә хезмәт итә. Автор әлеге усал тәнкыйть аша чынбарлыкны үзгәртүнең һәркемгә бәйле булуы, моның өчен үз күңелеңдә матурлыкка, сафлык-чисталыкка урын бирү кирәклеге турындагы нәтиҗәгә китерә.

«Җәйге кырау» драмасы белән Аманулла (Әмир Камалиев) кеше җанының катлаулылыгы, каршылыклы булуы, аны аңлап бетерү мөмкин түгеллеге турындагы бәхәскә кушыла. Әсәр үзенең психологизмы, кеше бәхете, аның рухи көче, өмет-ышаныч мәсьәләләре турында укучы-тамашачыны җитди уйлануга этәрүе белән уңышлы. Табигать күренеше булган җәйге кырау – көннәр җылына башлагач, кисәктән килгән салкын һава – яшь үсентеләрне, яңа ачыла башлаган бөреләрне юк итә. Әлеге күренеш пьесада Зөфәр язмышына метафора булып тора. Кыю, батыр һәм көрәшче егет мәхәббәтендә, үз-үзен тотышында, кешеләргә мөнәсәбәтендә хаталар ясый, шуның өстенә, үзе ышанган кешеләрнең хыянәтенә тап була. Зөфәр аларны үтеп чыгарга, тормышын яңадан башларга көч таба алмый һәм үзенә үзе кул сала.

Аманулла Зөфәр язмышын Ак сөлге символы аша аңлата. Й.Нигъмәтуллина фикеренчә, ул дүрт төрле символик мәгънәдә бирелә. Зөфәр төшендә әтисенең ак сөлге тапшыруын күрә, ә инде соңрак аңа, Сабантуй батыры буларак, ак сөлге бүләк итәләр. Берничә ел үткәч, эчкечелеккә сабышкан Зөфәр сөлгене аракыга алыштыруны сорый. Соңгы

---
[1] Тәрҗемә безнеке. – *Ә.З.*

күренештә исә ул әлеге сөлге белән асылынып үлә [12: 150-152]. Күргәнебезчә, ак сөлге башта ата-баба традициясен аңлатса, аннары ул осталык, көч, үз-үзеңә ышану билгесе булып тора. Зөфәрнең сөлгене аракыга алыштырырга омтылуы – бу инде традицияләрдән читләшү, гореф-гадәтләрне бозу, өмет-ышанычны югалту һәм рухи көчсезлек нәтиҗәсе буларак үлемгә бару. Драманың төп идеясен ачуда Сабантуй күренеше мөһим урын алып тора. Әсәрне модернистик концепция кысаларында тикшергән Й.Нигъмәтуллина болай дип яза: «Зөфәрнең ике төрле табигате үзара каршылыктагы ике хронотопта – Сабантуй һәм көндәлек гадәти тормыш хронотопларында ачыла»: [12: 150]. Әлеге милли бәйрәмнең башлангычы борынгы мифларга, йолаларга барып тоташа. «Әлеге календарь бәйрәмнең татарларның ерак бабаларында барлыкка килүе күк һәм кояш алласы Тәңре һәм борынгыларның рухы хөрмәтенә күмәкләшеп дога кылу һәм корбан китерү йоласы белән бәйле» [20: 216]. Барлык авылдашлары кебек үк Зөфәр дә әлеге Сабантуйга ашкынып, зур теләкләр белән кайта: Сабантуй батыры булып калу, сөйгән кешесенә мәхәббәтен аңлату һәм киләчәген туган җире, авылы белән бәйләү. Әмма егет гаделсезлек белән очраша, аннан партком секретаренә җиңелүне таләп итәләр. Горурлыгына кагылуны ул бик авыр кичерә. Көрәштә Баш батыр булып калса да, рухи җиңелүгә дучар була. Күңелендәге каршылыкларны хәмер белән «җиңгән» егет сөйгәнен югалта. Шул рәвешле, әсәрдә, бинар оппозицияләр буларак, милли үзенчәлекләр чор идеологиясе белән каршылыкка керә һәм Сабантуйның авылдашларны берләштерүгә хезмәт иткән изге вазифасы үзенең асылын югалта. Берничә кеше язмышы аша, драматург дуслык һәм хыянәт, мәхәббәт һәм мәкер, яшәү һәм үлем, куркыныч чиргә әверелгән эчкечелек кебек проблемаларны күтәрә. Драмадагы мифопоэтик катлам яшь кешенең гомере өзелү кебек фаҗиганең сәбәпләрен ачыклау, аны булдырмау юлларын ачарга ярдәм итә. Моның өчен милли традицияләрне яклау һәм саклау, тормышта үз-үзеңне табу, актив позициягә басып, гаделлек өчен көрәшкә чыгу кирәклеге автор белән укучы диалогы рәвешендә дәвам итеlә.

Р.Зәйдулланың «Ашина» драмасы нигезендә кешене рухи бөеклеккә китергән һәм түбәнлеккә төшергән сәбәпләр турында уйлану ята. Автор ике проблеманы бер үзәккә туплап бирә: 1) нахак гаеп белән төрмә-лагерьлар аша үткән кеше фаҗигасе, 2) сусаклагыч төзү аркасында, туып-үскән, ата-баба каны тамган җирен югалтучылар хәсрәте. Шуларга бәйле каршылык чишелеше көтелгәнчә түгел: җәмгыятьнең кешелексез ягын үз җилкәсендә татучы да, хакыйкатькә соңарып килүче дә, гомере буе көнчелек, үч, комсызлык афәтеннән котыла алмаучы да, су астында калып, мәңгелеккә күчәләр. Әмма яшь буын вәкилен, киләчәк кешесен бүре коткарып кала. Әлеге нәселнең башында торучы меңьяшәр бүре Ашина турындагы риваятьне оныгы Мирзага Ибраһим сөйли: «*Борын-борын заманда безнең халык зур тау тирәсендә яшәгән. Бервакыт аларның иленә дошман бәреп кергән дә олысын-кечесен кырып чыккан. Бер малай гына исән калган. Аны бер бүре тау куышына алып кайткан, яраларын дәвалаган, ашарына биргән. Бераздан бу малай егет булып үсеп җиткән. Ә бүре – ана бүре икән! – егеткә тугыз бала табып биргән. Безнең халык үрчеп, күбәеп җир йөзенә таралган. Шул бүренең – ерак әнкәбезнең! – исеме Ашина булган*».

М.Бакиров билгеләп үткәнчә, борынгы кешеләр ыруг яки кабилә нинди дә булса хайваннан, кош-корттан, үсемлек яки башка берәр тотем нәрсәдән барлыкка килгән дип караганнар, шуны теге яки бу кавемнең «бабасы» дип исәпләгәннәр һәм изгеләштергәннәр. Бу мифның нигезендә борынгы мифологик фикерләү формасы – тотемизм ята [21: 20]. Тотем – ыруг-кабиләнең нәсел башы, яклаучысы. Борынгы төрки кабиләләрнең тотемы булып, бүре, барс, елан һ.б. саналган. Әлеге риваятьнең әсәрдә сурәтләнгәннәр белән бәйләнеше Ватан, Намус, Ирек төшенчәләренең мәңгелек булуы турында уйлануларга да этәрә. Әсәрдәге вакыйгалар XX гасырның 60-70 еллары буларак күзаллана. Хөкүмәтнең уйланылмаган эш-гамәлләре аркасында, ата-бабалар яшәгән җирләр су астында кала. Яшәештә хөкем сөргән космик башлангыч, кешеләр күңелендәге курку, борчылу, аптырау аша, хаос хәле белән алышына. Моны хәл итү, бер яктан, геройлар өчен сынау булса, икенче яктан, капма-каршы көчләрнең көрәше дә булып тора. Вакыйга-күренешләрнең һәм конфликтның үзенчәлеге шунда: көрәшүче якларның эш-гамәле төрлечә бәяләнә ала, ягъни ике төрле укылышка урын кала. Аларны шәрехләү-бәяләү укучы-тамашачының шәхси карашы, позициясе белән тыгыз бәйле. Су

белән бүленеп калган утраудан Мирзаны бүре коткаруында билгеле риваятьнең кабатлануын күрәбез. Бу, бер яктан, Ибраһим нәселенең сакланып калуы, киләчәге символы булса, икенче яктан, тере табигать дөньясы белән кешенең бергәлегенә ишарә итә, өченчедән, гөнаһка батып та тәүбә итмәгән кешеләрнең Бөек көч тарафыннан җәзага тартылуы – су ташкыны белән юк ителүен белдерә. Соңгысына бәйләп Р.Зәйдулла бөтен дөньяны су басу турындагы мифтан файдалана. Пьесада ут мотивы да игътибарга лаек. Үзләренең хезмәте бушка китүне, печән өеменең инде беркемгә дә кирәк булмавын аңлаган Сабах аңа ут төртә. Ут мифологиядә җир һәм күк тормышының бергәлеген белдергән символ булып тора һәм киләчәктә кешеләрнең һәм «вакытлы», һәм «мәңгелек» дөньяда тынычлыкка, гаделлеккә нигезләнү омтылышын, теләген тудыра. Төрки халыкларда ут рухи чистарыну билгесен дә аңлата. Пьесада ул Ибраһимның төрмәгә утыртылуына гаепле икәнен аңлаган Сабахның соңарып булса да тәүбә итүенә ишарәли.

Д.Салиховның «Баязит» драмасы кеше яшәеше, аннан да бигрәк язучы иҗаты, киләчәк буынга васыяте булырга тиешле әсәренең кыйммәте, заман сынавын узу-узмавы турында уйлануларны, җитди фәлсәфи бәхәсләрне үз эченә ала. Драма үзенчәлекле төзелеш-структурага ия. 80 яшьлек олпат язучы Баязит гомеренең ахырына якынлашканын яхшы аңлый, әмма аның җанында тынычлык юк. Ул үткән тормышы, яшәеше, эш-гамәлләре турында уйлана. Аның хыялында үз тормышына бәйле вакыйгалар, якыннары, иҗат иткән әсәрләренең геройлары бер-бер артлы пәйда була. Аларны үзара бәйләп, тоташтырып тору максатында, автор шартлы Пәри образыннан файдалана. «Татар мифологиясендә, тылсымлы әкиятләрдә һәм язма әдәбиятта, бигрәк тә урта гасырларда киң таралган шактый каршылыклы персонаж» [2: 305] кешегә ярдәм итүче дә, явыз рух та, ягъни уңай да, тискәре дә булырга мөмкин. Җен-пәри дигәндә, шул күздә тотыла [6: 163]. Пәри – әсәрдә төп герой Баязитның күңелен, рухи дөньясын ачучы, аңарда барган җан бәргәләнүенә төшенергә, шуны тоемларга ярдәм итүче мифик образ. Драмада ул хакыйкатьне яклаучы, намус сакчысы буларак бирелә. Д.Салиховның мифик герое реаль чынбарлыкта – Баязит дөньясында хәрәкәт итә һәм төп конфликт Баязитның эчке күңелендә, җан-рухында барган көрәш белән бәйле [22: 182-183].

Аерым әсәрләрдә мифологик сюжет яисә образлар ачык күренеп тормаска да мөмкин, әмма текст мифологик төзелеш принципларына нигезләнә. «Әмма авторлар тарафыннан иҗат ителгән мондый әсәрләрдәге ситуацияләр һәм образлар, тарихи яктан конкрет булу белән бергә, үзләрендә, аларны конкрет-тарихилыктан югары күтәреп, универсаль онтологик характер бирә торган билгеле бер сыйфатка да ия булырга тиеш» [15: 14]. Хәзерге татар драматургиясендә андый пьесалар шактый урын алып тора (И.Юзеев «Ак калфагым төшердем кулдан» (1990), Т.Миңнуллин «Хушыгыз» (1992), «Шәҗәрә» (1998), «Дивана» (2006), З.Хәким «Кишер басуы» (1993), М.Гыйләҗев «Баскетболист» (2002), Ю.Сафиуллин «Йөзек һәм хәнҗәр» (1997) һ.б.).

М.Гыйләҗев «Баскетболист» драмасында, җәмгыятьтәге таркаулыкны, кешеләр күңелендәге битарафлыкны үтеп чыгу максатында, үзенең мифологик моделен тәкъдим итә. Бу, беренче чиратта, Сократның – яшәп килгән тәртипләрне бозучы, яңа идеяләр белән рухланучы, хәрәкәткә омтылучы геройның – эш-гамәле, теләк-максаты, ул яклаган әхлакый кыйммәтләр белән бәйле. Аның әлеге буталчык дөньяда үз-үзен табуы, шуңа башкаларны ышандыруы, иң мөһиме, кешеләр күңеленә өмет-ышаныч хисен салуы шәхси башлангыч кына булып калмыйча, бер үк вакытта, гомумәһәмиятле, кирәкле һәм җитди сыйфат-билге булып ачыла. Е.М.Мелетинский билгеләп үткәнчә, мифологизмның төп пафосы нәкъ менә яшәештәге ныклы, үзгәрешсез, мәңгелек башлангычларны ачыклауда чагыла [23: 295]. М.Гыйләҗев, аерым кешенең теләген сурәтләү аша, авыл халкының коллектив бергәлегенә, гармоник тәңгәллегенә омтыла. «Сократның тормышка ашмастай хыялы артында матур, камил яшәешкә омтылыш ята, нәкъ шул омтылыш кыйбласын югалткан күпләргә таяну ноктасына әверелә» [24: 33]. Әсәрнең мифопоэтик нигезендә урын һәм вакытның роле зур. Хронотоп үзенчәлеге капма-каршы төшенчәләр аша бирелә. Пьесадагы тормыш моделенең үзәгендә Балчыклы авылы тора. Ул куркыныч әйләнә-тирә белән әйләндереп алынган, текстта сазлык һәм туктаусыз яуган яңгыр символы аша бирелә. «Кыргый капитализм» шартларында кешеләр дә шундый ук сыйфатта ачыла. Бу урында бер кызыклы чагыштыру үткәрергә мөмкин. Прозаик

А.Гыйләҗевнең «Качак» (1959) хикәясендә дә тормыш үзгәрешләреннән артта калган Балчыклы авылы сурәтләнә, Тәнзилә исемле кыз әлеге авылны яңарту, кешеләрен үзгәртү теләге белән яши [20: 216]. М.Гыйләҗевнең дә әлеге исемгә мөрәҗәгать итүе юкка түгел. Бу күренеш, бер яктан, вакыйга-күренешләрнең кабатланып торуын аңлатса, икенче яктан, Балчыклы исеме Аллаһ кулы тигән «изге балчык» төшенчәсе белән бәйлелекне аңлата. Коръәндә әйтелгәнчә, «Аллаһ адәмне яндырылган чүлмәк кеби зыңгылдап торган (саф) балчыктан ясады» (Коръән, 55:14) [25: 501].

Әлеге авылны үзгәртү, кешеләрендә киләчәккә ышаныч хисе уяту изге бурыч буларак кабул ителә. Әсәр башында геройлар әлеге ямьсез, шыксыз чынбарлыкта югалып калу куркынычы янаган, җәмгыять тарафыннан кагылган-сугылган, ялгызлыкка дучар ителгән кешеләр булып күзаллана. Нәкъ менә Сократның яңа хыялы, идеясе аларда яклау таба һәм киләчәкләренә өмет хисе уята. Шул рәвешле, яшерен мифологик катлам яшәештәге хаос буларак кабул ителгән каршылыкларны үтеп чыгу юлларын, мөмкинлекләрен тирәнрәк ачарга ярдәм итә.

Т.Миңнуллинның «Дивана» драмасын да мифопоэтик яссылыкта тикшерүгә киң җирлек бар. Пьесада ике мәсьәлә калку куелган. Берсе – гармониягә нигезләнгән дөнья кору. Кешелек җәмгыятендә андый яшәешкә омтылу хыял буларак һәрвакыт булган. Әлеге теләк бүгенге тормыш шартлары белән дә аңлатыла. Пьесаның умыртка баганасын тәшкил иткән икенче проблема җанлы һәм җансыз табигать дөньясы, аның уртасындагы авыл белән бәйле. Драматургның соңгы еллар иҗатында урын алган бер үзенчәлек монда да чагылыш таба: ул кешенең сафлыгын-чисталыгын да, гадилек-гадәтилеген дә авыл белән бәйләп карый. Автор әлеге әсәрдә төзегән яшәеш моделенең үзәгендә дә авыл тора. Ул, әдәби мотив буларак, бинар позициядә «цивилизациягә» каршы куела. «Цивилизация» заман эшмәкәре, тупас Ким образында чагылса, «табигать» кочагындагы авыл беркатлы, самими Айсылу образында, аларның каршылыгында бирелә. Әсәр геройлары «бер генә дә нормаль кеше» булмаган шәһәрне кабул итмиләр. Авыл үзенең табигате белән дә кешене дәвалау көченә ия. Кешенең табигать белән гармониядә яшәү теләге мәхәббәт хисе белән кушылып китә.

Пьесадагы мифопоэтик эчтәлек аеруча тулы мотивларда ачыла. Аның берсе фәлсәфи һәм психологик планда чагылган ялгызлык мотивы белән бәйле. А.Шәмсутова билгеләгәнчә, ялгызлык нигезендә «кешенең фани дөньяга нинди вазифа белән килүен аңлау (…) һәм язмыш тарафыннан тормышының башкача билгеләнүе арасындагы каршылык» [14: 48] ята. Драманың төп герое Вил (Владимир Ильич Ленин исеменнән ясалган һәм совет чорында тудырылган миф чагылышы булып тора) шәһәр шартларында үз-үзен тапмаудан, гадел җәмгыять турындагы идеяләрен тормышка ашыру мөмкинлеге булмаудан тилмереп яши, хәтта авыру – дивана хәленә килә. Ул авылда да ялгыз, үз китаплары (Ленин томнары), үз дөньясы белән яши. Ә менә мәхәббәт кешенең рухи дөньясын ачуга һәм шуның белән психологик халәтен үзгәртүгә сәләтле көч буларак чагыла. Авыл кызы Айсылуга булган ярату хисе Вилнең авыруын җиңә. Кызганыч, шәһәргә киткәч, ул тагын ялгызлыкта кала һәм авырып психбольницага эләгә. Шул рәвешле, бөтен әсәрне иңләп үткән сызлану фәлсәфәсе автор караш-фикерләрен конкрет тарихилыктан гомуми, ягъни универсаль яссылыкта карауга, бәяләүгә китерә.

Үткән дәверләр әдипләре, аларның әсәрләре, геройлары алдагы чор язучылар өчен иҗатка этәргеч, яңа әдәби-фәлсәфи концепцияләргә материал булып тора һәм алар, гадәттә, яңа миф тудыруга да хезмәт итә. «Мифологиягә мөрәҗәгать итү татар халкының тарихи аңында сакланган архаик образларны, элементларны кабат өскә чыгаруга, аларны бүгенге укучының исенә төшерүгә, хәтерендә кабат яңартуга ярдәм итә» [14: 16]. Әдәбиятта, шул исәптән драматургиядә аерым шәхесләргә бәйле мифларның урын алуы XX йөз башына карый. Ул чорда «идеяләр романтизмы»на (Й.Нигъмәтуллина), ягъни җәмгыятьнең үзгәреш-яңарышын татарның милли үзаңы үсү белән бәйле тарихи шәхесләрнең әдәби образлары тудырыла (Сөембикә). Үз дәверенең бер феномены буларак, Тукай мифы барлыкка килә. Соңрак аның үрнәгендә башка язучыларга караган мифлар пәйда була. Үз вакытында һәм аннан соң күп тапкырлар тудырылган Тукай турындагы мифлар халык шагыйренең әдәбиятка, татар дөньясына алып килгән яңалыгы, андагы урыны белән бәйле. Бу күренешне фәндә Е.М.Мелетинский «мәдәни герой» («культурный герой») төшенчәсе белән атый. Тукай бүген дә халыкка хезмәт итү идеалы булып тора һәм символ дәрәҗәсенә күтәрелә.

В.Е.Хализев болай дип яза: «Әдәби тормышның соңгы ике йөз елында язучылар иҗат иткән мифка караганда, тирәлек, ягъни укучы публика, шул исәптән тәнкыйтьчеләр, галимнәр, публицистлар кабул итә торган әдәби фактлар турында миф тудыру әһәмиятлерәк булып тора. Шул рәвешле аерым әсәрләр һәм аларның геройлары, язучылар үзләре һәм аларның биографияләре, шулай ук әдәби юнәлешләр һәм дәверләр мифлаштырыла» [26: 14]. Алар арасында аеруча киң таралыш алганы – классик әдәбияттагы геройларны миф дәрәҗәсенә күтәрү. Башка халыклардагы кебек үк, татар әдәбиятында да китап укучыларда зур кызыксыну тудырган әдәби геройлардан Хәмзә бай (Г.Камал. «Беренче театр»), Галиябану (М.Фәйзи. «Галиябану»), Зөләйха (Г.Исхакый. «Зөләйха»), Әлмәндәр (Т.Миңнуллин. «Әлдермештән Әлмәндәр») һ.б. алдагы чорларда символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Моның үзенчәлеге шунда: алар әсәрдән аерым, ягъни мөстәкыйль яши башлыйлар, укучылар игътибарын милли яшәешнең аерым якларына юнәлтәләр яисә җитди фәлсәфи уй-фикергә, бәхәсләргә алып киләләр. Ә инде үз чорында киң яңгыраш алып, татар әдәбияты үсешенә көчле тәэсир иткән, үзеннән соңгы әдәбиятта миф дәрәҗәсенә күтәрелгән әсәрләр арасында Г.Камалның «Беренче театр»ы (1908), «Банкрот»ы (1911), Г.Исхакыйның «Зөләйха»сы (1912), М.Фәйзинең «Галиябану»ы (1916), К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл»е (1926), «Сүнгән йолдызлар»ы (1923), Н.Исәнбәтнең «Идегәй»е (1941), Т.Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»е (1975) һ.б. бар. Хәзерге сәхнә әдәбиятында әлеге әсәрләргә мөрәҗәгать итү, беренчеләре текстында икенчеләренең өзекләре, геройлары, аерым репликалары урын алу нәкъ менә әдәби һәм мәдәни миф чагылышы булып тора.

Т.Миңнуллинның «Галиябану, сылуым-иркәм» (2004) пьесасында әдәбият-сәнгать дөньясы, аның кеше тормышындагы урыны, төрле буын кешеләренең әдәби ядкәрләргә караш-мөнәсәбәте һәм, иң мөһиме, кеше яшәешенең, аның теләкләренең, борчу-мәшәкатьләренең тирән катламнарын ачу, шуларны аңларга омтылу тора. Әлеге катлаулы мәсьәләләрне укучы-тамашачыга җиткерү максатында, автор XX йөз башында яшәп иҗат иткән М.Фәйзинең атаклы «Галиябану»ы турында миф тудыра. Ул түбәндәгеләрдә чагылыш таба: беренчедән, Т.Миңнуллин М.Фәйзи әсәренә бәя бирә, үз чоры һәм бүгенгебез өчен кыйммәтен ача. 1916 елда дөнья күргән «Галиябану» мелодрамасы татар халкының иң яратып укылган һәм сәхнәдә каралган сәнгать әсәрләренең берсе булып тора. Сентименталь пафос белән өретелгән, саф хисләргә нигезләнгән мәхәббәткә мәдхия укылган, романтик самимилекләре, ихласлыклары белән башкалардан аерылып торган геройларның гаҗәеп матур хис-кичерешләре, шатлык-омтылышлары, кайгы-хәсрәтләре сурәтләнгән әсәр С.Сәйдәшевнең серле музыкасы белән кушылып үзгә бер яңгыраш ала, укучы-тамашачы рухына гаять көчле тәэсир итә. Пьесаны тулысы белән халыкның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, сыйфат-билгеләре, өмет-юанычлары иңләп үтә һәм әлеге күренешләр чын мәгънәсендә аһәңле, яңгырашлы, чиста-матур татар теле аша укучы-тамашачыга җиткерелә. Нәкъ менә шушы сыйфатлар «Галиябану»ны киң яңгырашлы итә һәм сәхнә әдәбияты тарихындагы урынын да билгели. Икенчедән, М.Фәйзи әсәрендә урын алган тема-мотивлар, мәсьәләләр Т.Миңнуллин әсәрендә заманга бәйләнештә яңгыраш таба. Өченчедән, М.Фәйзи әсәреннән алынган өзекләр Т.Миңнуллин пьесасының идея эчтәлеген, автор карашларын тулырак аңлауга хезмәт итә. Драматургның төп игътибары геройларның рухи дөньясын, хис-кичерешләрен ачуга юнәлтелгән. Үткән гомер, яшьлек хаталары, соңарып аңлашу күренешләренә бәйле тормышчан сораулар турында уйлану, бергәләп җавап эзләү пьесаның сюжет нигезен билгели. Әлеге драма, татар сәхнә әдәбиятында яңа юнәлешне башлап җибәргән пьеса традицияләрен дәвам итеп, аны яңа биеклеккә күтәрүгә хезмәт итә.

Шулай итеп, хәзерге татар драматургиясендә, яшәешнең гаять җитди мәсьәләләрен сурәтләүдә төрле әдәби-эстетик концепцияләргә нигезләнүгә бәйле, реализм һәм романтизм иҗат принципларының модернизм һәм постмодернизм юнәлешләренә хас элементлар, алым-чаралар белән үзара кушылып, үзенчәлекле синтез хасил итүе күзәтелә. Чынбарлыкны сәнгатьчә чагылдыруда драматурглар, бер яктан, борынгы мифологиягә мөрәҗәгать итсәләр, икенче яктан, әдәби текстның төрле өлеш-элементлары мифологик күзаллауларга нигезләнеп төзелә. Шул ук вакытта, авторлар, үткән чорлардан килә торган милли культура чагылышы буларак, аерым әдипләрне, аларның әсәрләрен, геройларын сәнгати фикерләүнең нигезе итеп алудан да

читләшмиләр. Мифопоэтик сурәтләүдә авторның дөньяны кабул итү үзенчәлекләре, шулай ук җәмгыять яшәешенең гомуми закончалыкларын ачу максатында социаль, мәдәни проблемаларны чагылдыру һәм әхлакый башлангычларны эзләү урын ала. Бу исә әсәрләрнең бер өлешендә тормыш-яшәешне җимерек халәттә, эсхатологик кабул итүгә китерә.

Әсәрләрнең төзелешендә, образларында, урын-вакыт бирелешендә файдаланылган мифопоэтика алымнары башкарган төп вазифалар түбәндәгеләр белән билгеләнә: әсәрнең сюжет нигезен оештыру; чынбарлыкның мөһим мәсьәләләрен калкытып кую һәм аларны хәл итү юлларын билгеләү; милли яшәеш үзенчәлекләрен коллектив күзаллау буларак торгызу; вакыйгалар хронотобы аша борынгы чорлар белән бүгенге арасындагы рухи һәм мәдәни бәйләнешләрне ачу; образларның яңа мәгънәләрен табу; әсәрнең сәнгати эшләнешен баету, төрләндерү һәм авторның әдәби-эстетик эзләнүләре юнәлешен билгеләү; бер әсәр кысаларында төрле стиль күренешләрен кушып җибәрү; татар халкының, киңрәк планда төрки, гарәп-фарсы халыкларының архетипларын актуальләштерү, традицион мотивларны, символларны трансформацияләү – яңа эчтәлек белән баету һ.б.

**Әдәбият**


1. *Бакиров М.Х.* Татарский фольклор. Казань: Ихлас, 2012. 400 с.
2. *Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1 т. (А-Г). Казан: Мәгариф, 2008. 303 б.
3. *Лотман Ю.М., Минц З.Г.* Литература и мифология // Учен.зап.Тартуского ун-та. Вып. 546. Труды по знаковым системам. Тарту. 1981. С. 35-56.
4. *Насыйри К.* Сайланма әсәрләр. 4 томда. 3 том. Казан: Татар.кит.нәшр., 2005. 384 б.
5. *Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман. Казан: Татар.кит.нәшр., 2000. 270 б.
6. Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар / Г.Гыйльманов хикәяләвендә. Казан: Татар.кит.нәшр., 1999. 432 б.
7. *Мәһдиев М.С.* Мифлар һәм аларның поэтикасы // Фольклор жанрларын система итеп тикшерү. Казан: КДУ нәшр., 1987. Б.3-25.
8. *Уразманова Р.К.* Татар халык йолалары һәм бәйрәмнәре. Казан: 1980. 96 б.
9. *Яхин А.Г., Мәһдиев М.С.* Халык иҗаты әсәрләрен система итеп тикшерү тәҗрибәсе. Казан: КДУ нәшр., 1982. 112 б.
10. *Урманче Ф.И.* Дастаннарга лаек замана. Борынгы фольклор һәм хәзерге поэзия. Казан: Татар.кит.нәшр., 1990. 222 б.;
11. *Урманче Ф.И.* Борынгы миф һәм бүгенге шигырь. Казан: Школа, 2002. 260 б.;
12. *Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: Фэн, 2002. 187 с.;
13. *Заһидуллина Д.Ф.* Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр: Монография. Казан: Мәгариф, 2006. 191 б.
14. *Шәмсутова А.А.* Хәзерге татар әдәбиятында яңарыш: фәнни мәкаләләр. Казан: Татар.кит.нәшр., 2010. 205 б.
15. *Ибрагимов М.И.* Миф в татарской литературе XX века: проблемы поэтики. Казань: Гуманитария, 2003. 64 с.
16. *Давлетшина Л.Х.* Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI вв. Казань: РИЦ «Школа», 2006. 140 с.
17. *Ибрагимов М.И.* Идея нового поэтического языка и мифотворчество в русской и татарской литературах 1920-х гг. // Вестник ТГГПУ. 2011. № 2 (24). С. 159-161.
18. *Йосыпова Н.М.* Хәзерге татар драматургиясендә интеллектуаль тенденция: М.Гыйләҗев // Ученые записки – 2007: сборник / научн.ред.И.А.Гилязов. Казань: Изд-во Казанск.гос.ун-та, 2008. С. 135-141.
19. *Азгамова Д.Р.* Миф в поэмах Г.Тукая «Шүрәле», «Су анасы », «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» и идея просвещения: механизмы взаимодействия // Вестник ТГГПУ. 2011. № 2 (24). С. 121-125.
20. *Хабутдинова М.М.* Мифопоэтическая основа повести А.Гилязова «Качак» («Беглец») // Вестник ТГГПУ. 2011. № 3 (25). С. 215-220.
21. *Бакиров М.Х.* Татар фольклоры: Югары уку йортлары өчен д-лек. Казан: Мәгариф, 2008. 360 б.
22. *Закирҗанов Ә.М.* Иҗат шатлыгы // Рухи таяныч. Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. Б. 176-189.
23. *Мелетинский Е.М.* Поэтика мифа. М.: Наука, 1976. 407 с.
24. *Заһидуллина Д.Ф.* XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. Казан: Казан университеты, 2011. Т.2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. 198 б.
25. *Коръән* аятьләренең татарча мәгънәләре һәм аңлатмалары / Матбугатка әзерләүче Р.Батулла. Казан, 2000. 572 б.
26. *Хализев В.Е.* Мифология XIX-XX вв. и литература // Вестник МГУ. 2002. № 3. С. 7-21.

# МИФОЛОГИЗМ В СОВРЕМЕННОЙ ТАТАРСКОЙ ДРАМАТУРГИИ

**Альфат Магсумзянович Закирзянов,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
alfat_zak@mail.ru.

В современной татарской драматургии ведутся серьезные поиски в разных направлениях. Авторы, наряду с реалистическим и романтическим изображением действительности, активно обращаются к сложным событиям человеческой жизни, которые зачастую невозможно понять и объяснить, а также пограничному состоянию человека, изображению его состояния в бинарных оппозициях. Драматурги, стремясь более полно и достоверно раскрыть это и донести до читателя, используют такие приемы и средства, как условность, метафоры, символы, мифы, архетипы и т.д. В последнее время авторы часто прибегают к использованию мифов в содержании произведений. Причиной, на наш взгляд, является стремление создать новую модель мира, изобразить действительность в тесной связи как с далеким прошлым человечества, так и внутренним миром отдельного человека, а также преподнести ценностно-смысловой мир самого автора.

В современной сценической литературе мы встречаемся со следующими видами мифологизма: 1) мифы, возникшие на основе верований и страхов далеких предков; 2) универсальные образы и явления, встречающиеся в культурах разных народов; 3) литературные факты, которые нашли свое место в истории как отражение культурных достижений национального сознания. В одних произведениях миф сохраняет свое первоначальное содержание, в других же видим его трансформацию, а в некоторых произведениях происходит разрушение мифа. В данной статье раскрываются особенности мифологизма в тесной связи с жанром, содержанием и формой произведения.

**Ключевые слова:** татарская драматургия, традиция, новаторство, миф, мифологизм, национальная особенность, новое содержание, образ, символ.